СОВЕТ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

16 декабрь 2019 ел г.Мензелинск № 4

“Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы территориясендә җирләрне саклау һәм файдалануга муниципаль җир контроле турында Нигезләмәне раслау турында” 24.10.2009 елдагы 22 нче номерлы Совет карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру максатларында, Россия Федерациясе Җир кодексының 72 нче статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы 06.10.2003 елдагы 131 нче Федераль законы, “Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында”гы 26.12.2008 елдагы 294 нче Федераль законы, “Татарстан Республикасында җирле үзидарш турында” 28.07.2004 елдагы 45 нче ТР законы, Минзәлә муниципаль районы Уставы нигезендә, Минзәлә муниципаль район Советы

КАРАР БИРДЕ:

1. “Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы территориясендә җирләрне саклау һәм файдалануга муниципаль җир контроле турында Нигезләмәне раслау турында” 24.10.2009 елдагы 22 нче номерлы Совет карарына үзгәрешләр кертергә:

1.1. “Тикшерүләр уздыру һәм беренчел документларны рәсмиләштерү тәртибе” бүлеген тулыландырырга:

- Җирле үзидарә органнары мәҗбүри таләпләрнең, муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләрнең үтәлеше мәсьәләләре буенча юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә мәгълүмат бирүне башкаралар, шул исәптән, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрнең, мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен семинарлар һәм конференцияләр уздыру, массакүләм мәгълүмат чараларында аңлату эшләре һәм башка ысуллар белән гамәлгә ашыралар.

Мәҗбүри таләпләр, муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләр үзгәргән очракта, муниципаль контроль органнары муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләр, мәҗбүри таләпләрне билгеләүче яңа

норматив хокукый актлар булу,сроклары һәм аларның гамәлгә керү тәртибе, шулай ук муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләр, мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен тәэмин итү һәм индерүгә юнәлтелгән кирәкле оештыру һәм техник чараларны уздыру турында реконмендацияләр турында комментарийларны әзерлиләр һәм таратталар, андый тикшерү предметы булып муниципаль контроль органы биргән күрсәтмәне үтәү генә була ала.

- Муниципаль контроль органы үтәлешенә бәя бирү муниципаль контроль предметы булган, муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләрне сыйдырган норматив хокукый актлар һәм аларның аерым өлешләре исемлекләрен “Интернет” челтәрендә рәсми сайтта урнаштыруны таләп итә.

- Җирле үзидарә органнары муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләрнең бозылуына юл куймау турында кисәтү игълан итәләр.

Кисәтүне кертү тәртибе “Муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләрнең һәм мәҗбүри таләпләрнең бозылуына юл куймау турында кисәтүне төзү һәм җибәрү Кагыйдәләрен раслау турында”гы 10.02.2017 елдагы 166 нчы номерлы Хөкүмәт карары белән расланган, андый кисәтүнең үтәлеше турында хәбәр язуы, андый кисәтүгә һәм аларны карауга каршы килүләргә юридик затның һәм шәхси эшмәкәрнең каршы килүләрен, мәҗбүри таләпләрнең бозылуын булдырмау турында кисәтүне төзү һәм җибәрү Кагыйдәләре белән җайга салынган;

-1.2.” Планнан тыш тикшерүне оештыру һәм уздыру” бүлеген түбәндәге абзацлар белән тулыландырырга:

Планнан тыш тикшерү уздыру өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләрнең һәм (яки) мәҗбүри таләпләрнең ачыкланган кимчелекләрен бетерү турында моңа кадәр бирелгән күрсәтмәне юридик затның, шәхси эшмәкәрнең үтәү срогы чыгу;

1.1) хокукый статус, эшчәнлекнең аерым төрләрен башкаруга махсус рөхсәт (лицензия) яки башка юридик әһәмияткә ия гамәлләрне башкару хокукына юридик заттан һәм шәхси эшмәкәрдән муниципаль контроль органына гариза керү, әгәр юридик затны, шәхси эшмәкәрне тиешле планнан тыш тикшерү уздыру рөхсәт (килешү), махсус рөхсәт (лицензия), хокукый статус бирү кагыйдәләре белән каралган булса;

2) Муниципаль контроль органының гражданнарның гаризаларын һәм мөрәҗәгатьләрен муниципаль контроль органнарына кергән алдан тикшерү яки карау, юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр белән үзара бәйләнешсез контроль буенча, шул исәптән, түбәндәге фактлар турында массакүләм мәгълүмат чараларыннан, җирле үзидарә органнарыннан мәгълүматне вазыйфаи затның нигезләп тапшыруы;

а) гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә зыян салу, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирасына (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләр), Россия Федерациясенең

музей фонды составына кертелгән аеруча кыйммәтле, шул исәптән уникаль, Россия Федерациясенең Архив фонды документларына, милли китапханә фонды, илнең иминлеге составына кергән. Аеруча тарихи. Фәнни, мәдәни әһәмияттәге документларга, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгуы;

б) гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә зыян салу, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирасына (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләр), Россия Федерациясенең музей фонды составына кертелгән аеруча кыйммәтле, шул исәптән уникаль, Россия Федерациясенең Архив фонды документларына, милли китапханә фонды, илнең иминлеге составына кергән. Аеруча тарихи. Фәнни, мәдәни әһәмияттәге документларга, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгуы;

в) кулланучыларның хокуклары бозылу (кулланучыларның, гражданнарның хокукларын яклау өлкәсендә федераль дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыручы органга мөрәҗәгать иткән очракта, гариза бирүче үз хокукларын яклау (торгызу) өчен юридик затка, шәхси эшмәкәргә мөрәҗәгате каралмаган яки гариза бирүченең таләпләре канәгатьләндерелмәгән очракта);

г) товарларны маркировкалауга таләпләрнең бозылуы;

- Әгәр шәхси эшмәкәрнең, аның вәкаләтле затының, җитәкченең яки юридик затның башка вазыйфаи затының булмавы, яки тикшерү уздыруның мөмкин булмавына китерүче юридик затның башка вазыйфаи затының яки җитәкченең, аның вәкаләтле вәкиленең, шәхси эшмәкәрнең башка гамәлләре (берни эшләмәүләре) белән бәйле рәвештә планлы һәм планнан тыш тикшерүне уздыру мөмкин булмаган очракта, муниципаль контрольнең вазыйфаи заты тиешле тикшерүне уздыру мөмкин булмавы турында сәбәпләрен күрсәтеп, акт төзи.

Бу очракта муниципаль контроль органы тиешле тикшерүне уздыру мөмкин булмавы турында акт төзелгәннән соң өч ай эчендә, юридик затның, шәхси эшмәкәрнең алдан хәбәр язуы җибәрмичә һәм планлы тикшерүләрнең еллык планына планлы тикшерүне кертмичә планнан тыш урынга чыгып тикшерү уздыру турында карар кабул итәргә хокуклы".

1.3. "Планнан тыш тикшерүне оештыру һәм уздыру" бүлеген түбәндәге абзацлар белән тулыландырырга:

Планлы (рейд) тикшерүләре, аеруча саклана торган табигый территорияләрне, урман кишәрлекләрен, аучылык биләмәләрен, сулыкларның акваторияләрен, эчке диңгез сулары районнарын, территориаль диңгезләрне, континенталь шельфларны һәм Россия Федерациясенең икътисад зонасын, аттракционнарны, транспорт чараларын (эчке су юлларында һәм портлар акваторияләрендә, эчке диңгез суларында, территориаль диңгездә, Россия Федерациясенең икътисады зонасында, автомобиль һәм шәһәр җир өсте транспортында, үзйөрешле машиналарда һәм башка төр техникада, тимер юл транспортының хәрәкәт итүче

составында, һава судноларында) аларны эксплуатацияләү барышында тикшерү планлы (рейдлы) биремнәр нигезендә үз компетенциясе чикләрендә муниципаль контрольнең вәкаләтле вазыйфаи затлары тарафыннан уздырыла.

Андый биремнәрне рәсмиләштерү һәм карап тоту һәм планлы караулар(рейдлар) һәм тикшерүләр нәтиҗәләрен рәсмиләштерү тәртибе Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимияте органнары, шулай ук җирле үзидарә органнары, дәүләт контроленең (күзәтчелеге) тиешле өлкәләрендә норматив-хокукый җайга салуны гамәлгә ашыручы башкарма хакимиятнең федераль органнары тарафыннан билгеләнә.

Планлы (рейд) караулар, тикшерүләр уздырганда муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләр, мәҗбүри таләпләрнең бозылуы ачыкланган очракта, дәүләт контроле (күзәтчелеге), муниципаль контроль органнарының вазыйфаи затлары үз компетенңиясе чикләрендә андый кимчелекләрне кисәтү буенча чаралар күрәләр, шулай ук дәүләт контроле (күзәтчелеге), муниципаль контроль органының җитәкчесенә әлеге Федераль законның 10 статья 2 өлеше 2 пунктында күрсәтелгән нигезләр буенча шәхси эшмәкәрнең, юридик затның планнан тыш тикшерүе билгеләнү турында карар кабул итү очен ачыкланган кимчелекләр турында мәгълүматларны язмача җиткерәләр.

Планлы (рейд) караулары конкрет юридик затка, шәхси эшмәкәргә карата уздырыла алмый һәм тикшерүне үзләре белән алмаштырырга тиеш түгелләр.

Тикшерүләрнең дәүләт контролен (күзәтчелек), муниципаль контролен гамәлгә ашырганда (исәпкә алуны тәэмин итү максатларында, әлеге Федераль законның 10 статья 2 өлеше 2 пунктында күрсәтелгән планна тыш тикшерүләрдән тыш, шул исәптән, лицензиянең гамәлдә булу срогын озынайту, лицензияне кабаттан рәсмиләштерү турында гариза тапшырган, лицензиатның, лицензия тапшыру турында гариза тапшырган лицензияне эзләүчегә карата), шулай ук аларның нәтиҗәләренең бердәм тикшерү реестры булдырыла. Тикшерүләрнең бердәм реестры федераль дәүләт мәгълүмати системасы булып тора. Россия Федерацияце Генераль прокуратурасы әлеге реестрның операторы булып тора.

Тикшерүләрнең бердәм реестрын формалаштыру һәм алып бару Кагыйдәләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан раслана. Күрсәтелгән кагыйдәләр белән түбәндәгеләр билгеләнә:

1) тикшерүләрнең бердәм реестрын булдыру һәм кертү тәртибенә таләпләр;

2) тикшерүнең учет номерын автомат режимында бирү тәртибе:

3) тикшерү, аның нәтиҗәләре һәм ачыкланган кимчелекләрнең нәтиҗәләрен бетерү һәм (яки) кисәтү буенча чаралар, әлеге мәгълүматны бу реестрга кертү сроклары һәм тәртибе турында мәгълүматны тикшерүнең бердәм реестрына кертелгән составы;

4) җирле үзидарә органнарына тапшырылырга тиеш мәгълүматларны тикшерүнең бердәм реестрына кертелгән составы, аны тапшыру тәртибе;

5) тикшерүләрнең бердәм реестрына кертелергә тиешле муниципалж контрольне гамәлгә ашыру турында башка мәгълүмат составы.

3. Тикшерүләрнең бердәм реестры операторы тикшерүләрнең бердәм реестрыннан түбәндәге һәркем ала алырлык мәгълүматны "Интернет" челтәрендә махсуслаштырылган сайтта урнаштыруны тәэмин итә:

1) тикшерүнең учет номеры;

2) әлеге Федераль законның 14 статья 2 өлеше 1-6 һәм 9 пунктларында каралган һәм муниципаль контроль, дәүләт контроле (күзәтчелеге) органы җитәкчесе, җитәкче урынбасары күрсәтмәсендә яки боерыгында күрсәтелгән мәглүмат;

3) тикшерү актында күрсәтелгән һәм әлеге Федераль законның 16 маддә 2 өлеше 1-6 пунктларында каралган мәгълүмат;

4) тикшерү нәтиҗәләрен күрсәтү (муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләр һәм мәҗбүри таләпләрне бозуны тикшерү барышында ачыкланганмы);

5) тикшерү уздырганда ачыкланган кимчелекләргә карата, юридик затка, шәхси эшмәкәргә ачыкланган кимчелекләрне бетерү һәм (яки) зыян китерүне булдырмау буенча чаралар уздыру турында, административ хокук бозу турында эш буенча производствоны тәэмин итү чараларын куллану, гаепле затларны административ җаваплылыкка тарту, моңа кадәр бирелгән рөхсәт язуларын, лицензияләрне, аккредитация аттестатларын, рөхсәт характерындагы башка документларны гамәлдән чыгару яки туктатып тору, продукцияне кире кайтарып алу, муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләрне һәм мәҗбүри таләпләрнең ачыкланган бозылуы турында материалларны муниципаль контроль органының, аларның вазыйфаи затларының тиешле карарларын һәм гамәлләренә (берни эшләмәүләре) дәгъва белдерү һәм андый дәгъва белдерүнең нәтиҗәләре турында дәүләт органнарына һәм муниципаль органнарга кабул ителгән чараларга күрсәтү.

Тикшерүләрнең бердәм реестрын алып бару, аңа тиешле мәгълүмат кертү һәм аны ачу Россия Федерациясенең дәүләт һәм башка закон белән саклана торган башка таләпләрен исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

1.4. "Планнан тыш тикшерүне оештыру һәм уздыру" бүлеген түбәндәге абзацлар белән тулыландырырга:

Тикшерү битләре (контроль сораулар исемлеге) Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган гомуми таләпләр нигезендә муниципаль контроль органы тарафыннан эшкәртелә һәм раслана, һәм җаваплары тикшерү предметы булган муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләр, мәҗбүри таләпләрне шәхси эшмәкәр, юридик зат тарафыннан үтәве яки үтәмәве турында бер мәгънәдә раслаучы сораулар исемлеген үз эченә ала.

Берләштерелгән планлы тикшерүләр уздырганда муниципаль контрольнең берничә органы белән эшкәртелгән һәм расланган берләштерелгән тикшерү битләре (контроль сораулар исемлеге) кулланылырга мөмкин.

Тикшерү уздыру нәтиҗәләре буенча тутырылган тикшерү битен кулланып (контроль сораулар исемлеге) тикшерү уздырганда, тикшерү бите (контроль сораулар исемлеге) тикшерү актына беркетелә.

Юридик зат, шәхси эшмәкәр планлы тикшерү уздырылу турында аны уздыру башланырга өч көннән дә соңармыйча, планлы тикшерү уздыру башлану турында дәүләт контроле (күзәтчелек), муниципаль контроль җитәкчесе, җитәкче урынбасары күрсәтмәсе яки боерыгы күчермәсен тапшыру турында хәбәр язуы белән почта аша заказ белән һәм (яки) көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән электрон документ һәм юридик затның, шәхси эшмәкәрнең электрон почта адресы буенча җибәрү аша хәбәр ителә, әгәр андый адрес юридик затларның бердәм дәүләт реестрында, шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрында күрсәтелгән яки муниципаль контроль органына шәхси эшмәкәр, юридик зат тарафыннан алданрак тапшырылган булса, яки башка мөмкин булган ысул белән хәбәр ителә.

Үз-үзләрен җайга салучы оешма әгъзаларының планлы тикшерүен уздырган очракта, муниципаль контроль органы планлы тикшерү уздырганда катнашу һәм булу мөмкинлеген тәэмин итү максатларында муниципаль контроль органы үз-үзләрен җайга салучы оешмага хәбәр итәргә бурычлы.

Үз-үзләрен җайга салучы оешма әгъзаларының муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләрне һәм мәҗбүри таләпләрне бозуы ачыкланган очракта, үз-үзләрен җайга салучы оешманың андый әгъзаларына планлы тикшерү уздырганда, планлы тикшерү уздыру тәмамланган көннән соң биш эш көне дәвамында ачыкланган кимчелекләр турында үз-үзләрен җайга салучы оешмага хәбәр итәргә бурычлы.

2. Гамәлдәге карар рәсми төстә басылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Финас-бюджет һәм җир-милек палатасына йөкләргә.

Совет рәисе А.Ф.Сәлахов